КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 31 август г.Казань № 1053

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 28 сентябрь, 875 нче карары белән расланган Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 28 сентябрь, 875 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 май, 398 нче; 2022 ел, 28 март, 277 нче; 2022 ел, 17 август, 850 нче; 2022 ел, 20 октябрь, 1116 нчы; 2023 ел, 18 февраль, 156 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның җиденче абзацында «гомумтаралган файдалы казылмалардан» сүзләреннән соң «һәм минераль эчә торган сулардан» сүзләрен өстәргә;

3.1 пунктның уналтынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүче, җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче яки салым агентының бердәм салым түләве сыйфатында күчерелгән акча суммасының кемгә каравы турында белешмә кәгазе формасын һәм

аны электрон рәвештә бирү форматын раслау хакында» 2022 елның 30 ноябрендәге ЕД-7-8/1129@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча агымдагы елның 1 гыйнварыннан заявка бирелгән датага кадәр бирелгән салым түләүче, җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче яки салым агентының бердәм салым түләве сыйфатында күчерелгән акча суммасының кемгә каравы турында салым органының белешмә кәгазе.»;

әлеге Тәртипкә 5 нче кушымтаның җиденче абзацында «гомумтаралган файдалы казылмалардан» сүзләреннән соң «һәм эчә торган минераль сулардан» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин